**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 9 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 90 мин.

## I бүлек

| Дөрес җавапларны билгеләгез |
|---|

1.“Үлемнән көчлерәк” (Самат Шакир) әсәренең жанры - ___________________

2. “Җомга көн – кич белән” әсәрен иҗат иткән язучы -___________________

3. Проза төренең жанрларын билгеләп, дөрес җавапны түгәрәккә алыгыз:

а) шигырь, хикәя, драма ә) трагедия, комедия, драма

б) роман, повесть, хикәя в) әкият, табышмак, җыр

## II бүлек

| Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез |
|---|

Яшәү чыганагы – Кояш нурын,
Җир җылысын саклап үзендә,
Күкрәкләргә терәп кисәр икмәк
Һәр табынның тора түрендә.
Икмәк - игенченең җан җылысы,
Җир-анага кадер-хөрмәте.
Яшәү тамыры улһәр йөрәкнең,
Әти-әни, Ватан һәм дә икмәк!
Бу сүзләрдә – тормыш мәгънәсе.
Бәхет, хезмәт, ирек, яшәү яме –
Шул сүзләргә бәйле һәммәсе.

1. Шигырьнең авторын һәм исемен күрсәтегез__________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

2. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез ___________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
____________________________________________________________________

3. Шигырьдә образ, хис тудыруда ярдәм иткән троплар, стилистик һәм лексик чараларны табыгыз ________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## III бүлек

Хикәя жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

## IV бүлек

IV бүлек биремнәренә җавап языгыз

...Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газинурлар, Матросовлар шикелле күкрәгең белән дошман амбразурасын каплауМы, әллә үзең ач чакта соңгы икмәк сыныгың белән бүлешүме? Кешеләр төрле-төрле булган кебек, батырлык та күптөрле шул.

Берәүләрне тормыш гомергә бер генә сыный. Кеше дөнья зилзиләләренә каршы үзенең кечкенәдән үк җыелып килгән гайрәтен, ана сөте белән кереп, тамырларына таралган көчен куя. Куя да өстенә ябырылып килгән бөтен авырлыкларны бер селтәнүдә юкка чыгара. Шул мизгелдә каушап калмаганнарны батыр диләр.

Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный. Алар күкрәкләре белән дошманның ялкын чәчеп торган дзотларын япмыйлар, галәм биеклекләренә күтәрелеп, дөньядагы барлык кешеләрнең карашларын

үзләренә юнәлтмиләр. Туктаусыз тамып торган тамчыдай, сиздерми генә, шау-шуларсыз гына эшлиләр. Беренче тамган тамчыны һичкем игътибарга алмый. Тама-тама ташны тишеп чыккач кына тамчыга сокланалар. Ә ташны тишеп чыкканчы, ай-яй озак тамасы бар!...

Ничә язлар көтәсе бар, ничә кышлар үтәсе бар...

1. Әсәрнең исемен, авторын языгыз

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

2. Әсәрнең жанрын билгеләгез ________________________________

3. “Батырлык” сүзе үз эченә нинди сыйфатларны ала? Санагыз_

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

4. “Батырлык” сүзенә бәйләп, троплар кулланып, кыска инша языгыз.

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________